МАГАРИФ

**ФИЛИАЛ АО «ТАТМЕДИА» «РЕДАКЦИЯ ЖУРНАЛА «МАГАРИФ»**

**Адрес:** 420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2
420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2

**«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ «МӘГАРИФ» ЖУРНАЛЫ РЕДАКЦИЯСЕ»**

**Тел:** +7 (843) 222-06-09
**E-mail:** magarif@tatmedia.com
magarif@bk.ru
**Сайт:** www.magarif-uku.ru

« 16 » « апреля » 2024 г. № 119

**Актаныш**
**муниципаль**
**районы башлыгы**
**Л.Р. Зариповка**

**Хөрмәтле Ленар Рафак улы!**

ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, «ТАТМЕДИА» АҖ белән берлектә «Мәгариф» педагогик журналы һәм ата-аналар, укучы балалар өчен «Гаилә һәм мәктәп» журналы нәшер ителә. Әлеге басмалар милли мәгарифне саклау һәм үстерү буенча зур эшләр башкара. Журналыбыз битләрендә һәрдаим республика һәм ил күләмендәге мәгариф сәясәтен, Татарстан Рәисе каршындагы татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясенең эшчәнлеген яктыртып барабыз.

Безнең журналларны алучы педагогларның укучылары төп һәм бердәм дәүләт имтиханнары буенча югары нәтиҗәләргә ирешә. Чөнки журналда ай саен БДИ буенча комиссия җитәкчеләренең эксклюзив материаллары басыла.

Журналларыбызда быел Азнакай, Актаныш, Лениногорск, Менделеевск, Әгерҗе, Сарман, Әлмәт, Нурлат, Буа, Түбән Кама, Кукмара, Балтач һәм башка районнардагы педагогларның, уку йортларының эшчәнлеге турында материаллар басылып чыкты. Сезгә хезмәттәшлек өчен рәхмәт белдерәбез.

Актаныш районы педагоглары да ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, Бөтендөнья татар конгрессы, Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты, ТР Мәгарифне үстерү институты ярдәмендә оештырылган «Авыл укытучысы», «Иң яхшы тарих укытучысы», «Моңлы саз чыңнары», «ФГОС буенча иң яхшы дәрес» кебек бәйгеләрдә актив катнаша алыр иде.

Шулай ук «Магариф.РФ.» электрон журналында да укытучы һәм тәрбиячеләргә үзләренең дәрес һәм шөгыль эшкәртмәләрен, сыйныфтан тыш

чара үрнәкләрен бастыру мөмкинлеге бар. Бу исә аттестация үтүче мөгаллимнәр өчен зур ярдәм.

Моның өчен «Мәгариф», «Гаилә һәм мәктәп» журналларына язылу кирәк.

Шуны исәпкә алып, 2024 елның икенче яртыеллыгына язылу кампаниясе башлануын хәбәр итәбез. Искәртеп үтәбез: журналларга Россия почтасының барлык бүлекчәләрендә элекке бәядән язылырга мөмкин («Мәгариф» журналы – язылу индексы – П2423, 6 айга язылу бәясе – 645 сум; «Гаилә һәм мәктәп» журналы – индексы – П2429, бәясе – 693 сум). Шулай ук китереп бирү шарты белән альтернатив рәвештә редакция аша язылу мөмкинлеге дә бар. Альтернатив язылу ике журналга да 570 сум тора.

Сездән язылу кампаниясен оештыруда ярдәмегезне сорыйбыз һәм безнең басмаларга укытучылар, тәрбиячеләр актив язылыр, үзара хезмәттәшлек матур нәтиҗәләр бирер дип ышанып калабыз.

**Хөрмәт белән, «Мәгариф» журналының баш мөхәррире – «ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры урынбасары:** **Сөмбел Таишева**